Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № XXIII-3**

Балык Бистәсе штп. 2017 елның 21 ноябре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында "Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны даими оештыру һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы Федераль законны һәм "Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны даими оештыру һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" гы Федераль законны гамәлгә ашыру хакында" 2015 елның 26 декабрендәге 107-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законын тормышка ашыру хакында

Район халкының пассажирлар йөртү ихтыяҗларын канәгатьләндерү максатларында һәм "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 маддәсе, "Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында" 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы Федераль закон, "Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында"гы Федераль законны тормышка ашыру турында" 2015 елның 26 декабрендәге 107-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы

Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә гомуми файдаланудагы автомобиль транспортында пассажирлар йөртүне оештыру тәртибен расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетын Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы чикләрендә “Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында” 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы Федераль закон белән җирле үзидарә органнарына йөкләнгән даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру функцияләрен гамәлгә ашыруга вәкаләтле Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органы булып тора, дип билгеләргә.

3. “Татарстан Республикасы территориясендә гомуми файдаланудагы автомобиль һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар йөртүне оештыру турында” 2006 елның 13 октябрендәге 70-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру хакында” 2008 елның 21 декабрендәге XXXIII-5 номерлы Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык  Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

5. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны транспорт, төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык  Бистәсе муниципаль
район Советы рәисе И.Г. Вәлиев

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советының
2017 елның 21 ноябрендәге
XXIII-3 номерлы карары белән
расланды

# Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә гомуми файдаланудагы автомобиль транспортында пассажирлар йөртүне оештыру ТӘРТИБЕ

## 1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Тәртип "Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында" 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы чикләрендә урнашкан ике һәм аннан күбрәк җирлек чикләрендә гомуми файдаланудагы автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру мөнәсәбәтләрен җайга сала (алга таба - пассажирлар йөртүне оештыру), шул исәптән даими рәвештә пассажирлар йөртү маршрутларын билгеләү, үзгәртү, гамәлдән чыгару, даими йөртү маршрутлары реестрларын алып бару һәм муниципаль маршрутлар буенча даими йөртүләрне гамәлгә ашыруның башка оештыру нигезләре тәртибен.

2. Әлеге Тәртипнең гамәли көче ташу шартнамәсеннән барлыкка килә торган мөнәсәбәтләргә, шулай ук башка мөлкәти һәм алар белән бәйле шәхси мөлкәти булмаган мөнәсәбәтләргә кагылмый, аларны җайга салу гражданлык законнары белән гамәлгә ашырыла.

3. Әлеге Тәртип Россия Федерациясе Граждан кодексы, "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, "Юл хәрәкәте иминлеге турында"1995 елның 10 декабрендәге 196-ФЗ номерлы Федераль закон, "Россия Федерациясендә автомобиль транспорты һәм шәһәр җир өсте электр транспорты уставы" 2007 елның 8 ноябрендәге 259-ФЗ номерлы Федераль закон, "Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында" 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - Федераль закон), "Автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар йөртү һәм багаж ташу кагыйдәләрен раслау турында" Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2007 елның 14 февралендәге 112 номерлы карары, "Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр

транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында” Федераль законны гамәлгә ашыру турында” 2015 елның 26 декабрендәге 107-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба - 2015 елның 26 декабрендәге 107-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы), Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә эшләнде.

4. Әлеге Тәртипнең таләпләре барлык юридик затлар тарафыннан оештыру-хокукый рәвешләренә һәм милек рәвешләренә бәйсез рәвештә, шулай ук Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыручы юридик зат буларак оештырылмыйча гына индивидуаль эшкуарлар өчен мәҗбүри.

5. Әлеге Тәртипнең төп бурычлары түбәндәгеләр:

1) пассажирлар ташуга халыкның ихтыяҗларын канәгатьләндерүне тәэмин итү;

2) пассажирлар йөртүнең сыйфатын күтәрү;

3) ташучыларның транспорт дисциплинасын ныгыту;

4)пассажирлар йөртүне гамәлгә ашырганда юл хәрәкәте иминлеген арттыру;

5) ташучылар арасында намуслы көндәшлекне тәэмин итү;

6) пассажирлар йөртү белән муниципаль идарә итүнең нәтиҗәлелеген арттыру;

7) пассажирлар йөртүнең иң нәтиҗәле оештыруны тәэмин итү;

8) Россия Федерациясе законнары, Татарстан Республикасы законнары, муниципаль хокукый актлар нигезендә башка бурычлар.

6. Әлеге Тәртиптә кулланыла торган төшенчәләр Федераль закондагы мәгънәләрендә кулланыла.

Әлеге Тәртип белән җайга салынмаган пассажирлар йөртүне оештыру мөнәсәбәтләренә карата Федераль закон, 2015 елның 26 декабрендәге 107-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нормалары кулланыла.

## 2 бүлек. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының пассажирлар йөртүне оештыру өлкәсендәге вәкаләтләре

7.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Башкарма комитеты:

1) үз компетенциясе чикләрендә даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыруны җайга сала торган норматив хокукый актлар кабул итә;

2) үз компетенциясе чикләрендә даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны планлаштыру документын әзерләү тәртибен раслый, аны кабул итә һәм тормышка ашыра;

3) даими рәвештә пассажирлар йөртүнең муниципаль маршрутлары буенча даими рәвештә йөртү муниципаль заказчысы функцияләрен башкара,

муниципаль контракт төзи, муниципаль контракт шартларының үтәлешен контрольдә тота һәм даими йөртү маршруты карталарын бирә;

4) җайга салынмый торган тарифлар буенча даими йөртүләрнең муниципаль маршрутлары буенча йөртү хокукына ачык конкурс (алга таба – ачык конкурс)оештыручы функцияләрен башкара, ачык конкурста катнашу өчен гаризалар критерийларын бәяләү өчен шкаланы билгели, пассажир йөртүчеләргә даими рәвештә пассажирлар йөртү маршруты буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру турында таныклык һәм даими пассажирлар йөртү маршруты картасын бирә, аларның эшчәнлеген контрольдә тота;

5)даими рәвештә пассажирлар йөртүнең муниципаль маршрутлары реестрларын алып бару тәртибен, муниципаль маршрутларны билгеләү, үзгәртү, гамәлдән чыгару тәртибен раслый, даими йөртүләрнең муниципаль маршрутлары реестрын алып бара, даими йөртүләрнең муниципаль маршрутларын билгели, үзгәртә һәм юкка чыгара;

6)Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә урнашкан тукталыш пунктлары исемлеген билгели, аларны муниципаль ташу маршрутлары буенча башлангыч һәм (яки) соңгы тукталыш пунктлары итеп кулланырга рөхсәт ителәә;

7) даими пассажирлар йөртүне оештыру өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органына Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә муниципальара маршрутлар буенча тукталыш пунктларын билгеләү буенча тәкъдимнәр җибәрә;

8)кирәк булганда җайга салынмый торган тарифлар буенча даими йөртүләрнең муниципаль маршрутлары буенча йөртү таләпләрен билгели;

9) федераль башкарма хакимият органнары, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары белән даими рәвештә пассажирлар йөртүне оештыру һәм аларның гамәлгә ашырылуын тикшереп тору мәсьәләләре буенча хезмәттәшлек итә;

10) федераль закон, 2015 елның 26 декабрендәге 107-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы һәм башка муниципаль хокукый актлар белән аның компетенциясенә кертелгән башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

## 3 бүлек. Даими рәвештә пассажирлар йөртүнең муниципаль маршрутларын билгеләү, үзгәртү, гамәлдән чыгару тәртибе

8. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә даими рәвештә пассажирлар йөртүнең муниципаль маршрутларын билгеләү, үзгәртү, гамәлдән чыгару тәртибе (шул исәптән әлеге маршрутларны билгеләүдән яисә үзгәртүдән баш тарту өчен нигезләр)

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән билгеләнә.

## 4 бүлек. Даими йөртү маршрутлары реестры

9.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары реестрларын алып бару тәртибе Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән билгеләнә.

## 5 бүлек. Даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу төрен үзгәртү

10.Даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршруты буенча гамәлгә ашырыла торган даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның төрен үзгәртү, әлеге карар даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны планлаштыру документында каралган очракта, рөхсәт ителә.

11. Даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутын билгеләгән Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның төрен үзгәртү турында карар кабул итеп әлеге карар турында тиешле маршрут буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыручы гади ширкәт шартнамәсендә катнашучы вәкаләтле юридик затка, шәхси эшкуарга күрсәтелгән карар үз көченә кергән көнгә кадәр йөз сиксән көннән дә соңга калмыйча хәбәр итә.

12. даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу төрен үзгәртү турындагы мәгълүматлар Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының карары белән билгеләнгән тәртиптә даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршрутлары реестрына кертелә.

## 4 бүлек. Җайга салына торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру

13. Халыкның транспорт хезмәтләреннән файдалана алуын тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты Федераль закон нигезендә җайга салына торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру өчен даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутларын билгели.

14. Җайга салына торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру, Федераль закон нигезләмәләрен исәпкә алып, дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы

Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба - муниципаль заказчы) тарафыннан муниципаль контрактлар төзү юлы белән тәэмин ителә.

15. Муниципаль контракт предметы – муниципаль контракт төзелгән юридик зат, шәхси эшкуар (алга таба - подрядчы) тарафыннан җайга салына торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыруга бәйле эшләрне муниципаль заказчы билгеләгән таләпләр нигезендә башкару.

16. Муниципаль контракт муниципаль заказчы исеменнән бирелгән һәм даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның барлык маршрутлары буенча пассажирлар йөртү хокукын раслаучы билетлардан файдалануны күздә тота ала, аларга карата муниципаль заказчы муниципаль контрактлар төзегән.

17. Муниципаль заказчы тиешле контрактны үтәү өчен кирәкле транспорт чараларының максималь саны нигезендә даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның маршрут картасы муниципаль контрактның гамәлдә булу срогына бирә.

18. 2015 елның 26 декабрендәге 107-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары буенча җайга салына торган тарифлар тарифларны җайга салу өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы тарафыннан билгеләнә.

## 5 бүлек. Җайга салынмый торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру

19. Әлеге Тәртипнең 13 пунктында күрсәтелгән даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның маршрутлары белән беррәттән, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җайга салынмый торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру өчен даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутларын билгели.

20. Даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршруты буенча җайга салынмый торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу хокукы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә үткәрелә торган ачык конкурс нәтиҗәләре буенча бирелгән даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның тиешле маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында таныклык һәм даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның тиешле маршруты карталары белән раслана.

21. Даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршруты картасы тиешле маршрут буенча даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өчен кулланыла торган һәр транспорт чарасына бирелә. Мондый карталар саны әлеге маршрутка карата даими

рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршрутларының тиешле реестрында күрсәтелгән транспорт чараларының максималь санына туры килергә тиеш.

22. Җайга салынмый торган тарифлар буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыруга таләпләр кирәк булганда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының муниципаль хокукый акты белән эшләнә һәм раслана (2015 елның 26 декабрендәге 107-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 4 маддәсендәге 7.1 пунктын исәпкә алып).

## 6 бүлек. Даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршруты һәм тиешле маршрут карталары буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында таныклык бирү

23. Даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында таныклык һәм тиешле маршрут карталары әлеге маршрутны билгеләгән Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы башкарма комитеты тарафыннан бирелә.

24. Даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында таныклык һәм тиешле маршрут карталары ачык конкурс нәтиҗәләре буенча Федераль законда билгеләнгән тәртиптә бирелә.

25. Даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында таныклык һәм тиешле маршрут карталары ачык конкурс үткәрмичә генә даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән очракта бирелә:

1) Федераль законның 29 маддәсендәге 1 өлешенең 1 һәм 2 пунктларында каралган шартлар барлыкка килгәннән соң һәм даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны ачык конкурс уздыру нәтиҗәләре буенча бирелгән даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында яңа таныклык нигезендә гамәлгә ашыра башлаганчыга кадәр;

2) гадәттән тыш хәл шартларында халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне тәэмин итү максатларында билгеләнгән даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты буенча.

26. Ачык конкурс үткәрмичә даими рәвештә пассажирлар йөртү маршруты буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру турында таныклык бер тапкыр бирелә, ул йөз сиксән көннән артып китә алмый, аларны бирү өчен нигез булган шартлар җиткән көнне.

## 7 бүлек. даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташу маршруты карталарын гамәлгә ашыру турында таныклыкның гамәлдә булуын туктату яисә туктатып тору

27. Федераль законның 29 маддәсендәге 1 өлешендә билгеләнгән шартларның берсе генә булса да булуы нәтиҗәсендә даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында таныклыкның гамәлдә булуы Федераль законның 29 маддәсендәге 2 - 4 өлешләрендә билгеләнгән тәртиптә туктатыла.

28. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы башкарма комитеты түбәндәге шартларның берсе генә булса да барлыкка килгәндә даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында таныклыкның гамәлдә булуын туктату хакында гариза белән судка мөрәҗәгать итә:

1) даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршруты буенча әлеге таныклыкта каралган гадәттән тыш хәл булмаганда өч көннән артык вакыт дәвамында булмаган очракта;

2) бер ел дәвамында берничә тапкыр әлеге таныклык бирелгән гади ширкәт шартнамәсендә катнашучыларның берсе генә булса да, юридик затны, индивидуаль эшкуарны әлеге таныклыкта каралган пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашырганда Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 11.33 маддәсендәге 3 - 5 өлешләрендә күрсәтелгән административ хокук бозуларны кылган өчен административ җаваплылыкка тарту;

3) гади ширкәт шартнамәсен өзү (әлеге таныклык гади ширкәт шартнамәсендә катнашучыларга бирелгән очракта);

4) йөртүче гаебе белән кеше сәламәтлегенә авыр зыян салуга китергән юл-транспорт һәлакәте кылынган;

5) күрсәтелгән таләпләр Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан билгеләнгән очракта, җайга салынмый торган тарифлар буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыруга карата муниципаль норматив хокукый актта билгеләнгән таләпләрне бер ел эчендә кабат бозу.

29. даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршруты карталарының гамәлдә булуы әлеге маршрут буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында таныклыкның гамәлдә булуы туктатылган көннән, ә даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташу әлеге контрактның гамәлдә булуы туктатылган көннән, әлеге контрактның гамәлдә булуы туктатылган көннән алып туктатыла.

30. Даими рәвештә пассажирлар йөртүнең муниципаль маршруты буенча йөртү турындагы таныклыкның гамәлдә булуы, җайга салынмый торган тарифлар буенча даими йөртүләрне гамәлгә ашыру өчен бирелгән даими йөртүләрнең муниципаль маршрут карталарының гамәлдә булуы автомобиль транспортында пассажирлар йөртү эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензиянең гамәлдә булуы туктатылган очракта туктатып торыла.

## 8 бүлек. Даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында хисаплар

31. Юридик зат, индивидуаль эшкуар, муниципаль контракт төзелгән яисә даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында таныклык бирелгән гади ширкәт шартнамәсенең вәкаләтле катнашучысы Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетына, әлеге муниципаль контракт төзегән яки әлеге таныклыкны биргән яисә әлеге таныклыкны биргән башкарма хакимиятнең транспорт өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм норматив-хокукый җайга салу функцияләрен башкаручы федераль органы билгеләгән форма һәм срокларда даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында квартал саен хисаплар җибәрергә тиеш.